КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 4 декабрь г.Казань № 1099

Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында

Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү буенча «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итүне оештыру мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлек регламентын.

2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына балалар кирәк-яраклары җитештерүче Татарстан Республикасы предприятиеләре белән бүләк комплектын тутыру өчен әйберләр чыгару эшен оештырырга.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләренең хатын-кызлар консультацияләрендә (кабинетларында) йөклелек чорында диспансер күзәтүендә торучы хатын-кызларга 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан

башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү хокукы турында мәгълүмат бирү хакында норматив документ эшләргә.

4. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин